КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 14 июль г.Казань № 572

Агросәнәгать комплексына грант
ярдәме чаралары турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Бюджет учреждениеләренә һәм автоном учреждениеләргә агросәнәгать комплексы өлкәсендә фәнни тикшеренүләргә һәм эшләнмәләргә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан грантлар бирү тәртибен;

Кече эшмәкәрлек субъектларын үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган «Агропрогресс» грантларын бирү тәртибен;

Гаилә фермаларын үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган грантлар бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган грантлар бирү тәртибен;

Хуҗалыкларны төзү һәм (яки) үстерү проектларын тормышка ашыруга бәйле булган һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслана торган «Агростартап» грантларын бирү тәртибен.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин